ЯКШӘМБЕ
17
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 14 (6736)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

I.

ВОРОНЕЖДАН КӨНЬЯКТАРАК БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘРНЕҢ УҢЫШЛЫ ҺӨҖҮМЕ

Воронеждан көньяктарак урнашкан безнең гаскәрләр шушы көннәрдә немец-фашист гаскәрләренә каршы һөҗүмгә күчтеләр. Һөҗүм өч юнәлештә башланды: **Селявное** һәм **Щучье** районнарыннан көньяк-көнбатышка, **Кантемировка** районыннан төньяк-көнбатышка һәм көнбатышка таба. Безнең гаскәрләр, Селявное районында дошманның көчле рәвештә ныгытылган оборонасын 45 километр озынлыкта, Щучье районында 50 километр һәм Кантемировка районында 60 километр озынлыкта өзеп, көчле сугышларның өч көне эчендә, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, 50—90 километр алга киттеләр. Безнең гаскәрләр халык яши торган 600 дән артык пунктны, шул исәптән **Россошь** шәһәрен һәм тимер юл узелын, **Ольховатка, Митрофановка, Пухово** район үзәкләрен һәм тимер юл станцияләрен, **Репьевка, Красное, Ровеньки, Марковка, Каменька** район үзәкләрен, **Мелогорье, Рыбальчино, Сотницкое** тимер юл станцияләрен алдылар.

Безнең гаскәрләрнең һөҗүме барышында дошманның 9 пехота дивизиясе, шулардан 3 немец дивизиясе һәм 6 венгер дивизиясе тар-мар ителде.

Сугышларның өч көне эчендә 17.000 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды.

Шул ук вакытта, тулы булмаган саннарга караганда, безнең гаскәрләр түбәндәге трофейларны **кулга төшерделәр:** танклар—75, төрле калибрдагы орудиеләр—800, минометлар—493, пулеметлар—1.200, винтовкалар—14.000, автомашиналар—520, тракторлар—130, повозкалар—672, атлар—700, радиостанцияләр—21, снарядлар—350.000, патроннар—5 миллионнан артык, сугыш припаслары, снаряжениеләр һәм азык тутырылган складлар—70. Трофейларның санын алу дәвам итә.

Дошманның 135 танкысы, 210 орудиесе, 17 самолеты **юк ителде.**

Сугышларның өч көне эчендә дошман, үтерелгән хәлдә генә дә, 15.000 гә якын солдат һәм офицерларын югалтты.

Дошман оборонасын өзү Воронеж фронтының генерал лейтенант иптәш **Ф. И. Голиков** командалыгындагы һәм Көньяк-Көнбатыш фронтның генерал полковник иптәш **Н. Ф. Ватутин** командалыгындагы көчләре белән тормышка ашырылды. Һәр ике фронтның хәрәкәтләрен берләштерүне Верховный Баш Командование Ставкасы вәкиле генерал-полковник **А. М. Василевский** тормышка ашырды.

Сугышларда генерал-майор иптәш **К. С. Москаленко,** генерал-лейтенант иптәш **Ф. М. Харитонов,** генерал-майор иптәш **П. М. Зыков** гаскәрләре, генерал-майор иптәш **П. С. Рыбалконың** танк берләшмәләре һәм генерал-лейтенант иптәш **С. В. Соколовның** кавалерия берләшмәләре үзләрен аеруча күрсәттеләр.

II.

СТАЛИНГРАД РАЙОНЫНДА ЧОЛГАНЫП АЛЫНГАН НЕМЕЦ-ФАШИСТ ГАСКӘРЛӘРЕН БЕТЕРҮ ТӘМАМ БУЛЫРГА ЯКЫНЛАШЫП КИЛӘ

«Сталинградка килү юлларында безнең гаскәрләрнең 6 атналык һөҗүме йомгаклары» нда Совет Информбюросы хәбәр иткәнчә, 1942 нче елның 19 нчы ноябреннән башлап һөҗүм вакытында Кызыл Армия, Сталинград районында дошманның 22 дивизиясен тыгыз бозҗра белән чолгап алып, гаять кыен операцияне кыска срок эчендә уңышлы итеп үткәрде. Чолганып калган дошман гаскәрләре арасында 3 танк дивизиясе, 3 моторлаштырылган дивизия, 15 пехота дивизиясе һәм 1 кавалерия дивизиясе бар. Болардан тыш тагын немецлар армиясе баш командованиесе резервының 3 артиллерия полкы, 4 зенит полкы, 1 миномет полкы һәм 4 аерым сапер батальоны чолгап алынды.

Сталинградтан төньяк - көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләрнең һөҗүме башланган вакытта Сталинград янында хәрәкәт иткән немец армияләре, армия һәм корпус тыллары белән бергә, 200—220 меңгә якын кешедән тора иде. 1942 нче елның 23 нче ноябреннән башлап бу гаскәрләр тулы чолганыш хәлендә торалар.

Немец-фашист гаскәрләрнең Сталинград янында тулысынча чолганып алынуларына кадәр ук Кызыл Армия немецларның **44 нче,** 376 нчы һәм 384 нче дивизияләрен бөтенләй тар-мар итте. Аларның калдыклары хәзер чолганып алынган дошман гаскәрләре арасында. Соңгы атналарда безнең гаскәрләр, һавадан системалы рәвештә бомбага тотып, куәтле артиллерия уты белән һәм коры җир гаскәрләренең атакалары белән дошманның чолганып алынган группировкасының бик күп солдатларын һәм офицерларын кырдылар.

Шуның өстенә, чолганып алынган немец-фашист гаскәрләр, азык китерү юлларыннан мәхрүм ителгәнлектән, һәлакәтле хәлгә төштеләр. Чолганып алынган немец солдатлары көненә бары 100—150 шәр грамм гына икмәк алалар. Чолганып алынган гитлерчы частьларның күбесендә инде үлгән атлар да ашалып бетте. Германия командованиесенең үз гаскәрләренә транспорт авиациясе ярдәме белән азык китерергә маташуы җимертелде. 19 нчы ноябрьдән 10 нчы январьга кадәр Сталинград янында 600 дән артык транспорт самолеты атып төшерелде. Ачлык һәм хәлдән таю нәтиҗәсендә солдатлар арасында йогышлы авырулар тарала. Кыр госпитальләре күптән инде барлык яралыларны һәм авыруларны урнаштыра алмыйлар. Шуның өстенә Сталинград янындагы немец солдатларының кышкы киемнәре юк. Туңып үлүчеләр саны көннән-көн арта. Пленныйларның әйтүенчә, хәлсезлектән һәм кырда өшүдән генә дә көн саен 400—500 солдат үлә, ә барлыгы Сталинград янында чолганып алынган немец гаскәрләре көн саен кимендә 1.500 солдат югалталар.

Шушыларның бөтенесе нәтиҗәсендә немец-фашист гаскәрләр, Сталинград янында чолганып алынганнан бирле бик күп кешеләрен югалттылар. Хәзерге вакытта чолганып алынган немец-фашист гаскәрләренең личный составы 70—80 мең кешедән артмый.

Кызыл Армиянең Верховный Баш Командованиесе Ставкасы вәкиле артиллерия генерал полковнигы Н. Н. Воронов һәм Дон фронты гаскәрләре командующие генерал лейтенант К. К. Рокоссовский йөзендә Совет командованиесе, тиешсезгә кан түкмәс өчен, Сталинград янында чолганып калган Германия гаскәрләренең командованиесенә һәм бөтен офицерлар һәм рядовойлар составына 1943 нче елның 8 нче январенда түбәндәге ультиматумны бирде:

«Германиянең 6 нчы армиясе командующие генерал-полковник Паулюска яки аның урынбасарына һәм Сталинград янында чолганып алынган Германия гаскәрләренең бөтен офицерлар һәм рядовойлар составына.

Германиянең 6 нчы армиясе, 4 нче танк армиясе берләшмәләре һәм аларны көчәйтү өчен бирелгән частьлар 1942 нче елның 23 нче ноябреннән бирле тулы чолганыш хәлендә торалар.

Кызыл Армия частьлары Германия гаскәрләренең бу группасын тыгыз бозҗра белән чолгап алдылар. Көньяктан һәм көньяк-көнбатыштан Германия гаскәрләренең һөҗүм итүләре юлы белән сезнең гаскәрләрне коткаруга булган өметләр берсе дә акланмады: сезгә ярдәмгә ашыккан Германия гаскәрләре Кызыл Армия частьлары тарафыннан җимерелделәр һәм бу гаскәрләрнең калдыклары Ростовка чигенәләр.

Германиянең сезгә ачтан үлмәслек кенә азык, сугыш припаслары һәм ягулык китерә торган транспорт авиациясе, Кызыл Армиянең уңышлы, омтылышлы рәвештә алга баруы нәтиҗәсендә, аэродромнарны еш алыштырырга һәм чолганып алынган гаскәрләр янына ерактан очып килергә мәҗбүр була. Шуның өстенә рус авиациясе Германиянең транспорт авиациясенең гаять күп самолетларын һәм экипажларын юк итә. Чолганып калган гаскәрләргә Германия авиациясенең ярдәме нәтиҗәсез булып бара.

Сезнең чолганып алынган гаскәрләрегезнең хәле авыр, алар ачлык, авыру һәм салкынлык кичерәләр. Рәхимсез рус кышы әле башлана гына. Көчле салкыннар, салкын җилләр һәм бураннар алда әле, ә сезнең солдатларыгыз кышкы киемнәр белән тәэмин ителмәгәннәр һәм санитария ягыннан авыр шартларда торалар.

Сез, командующий буларак, һәм чолганып алынган гаскәрләрнең барлык офицерлары бик яхшы аңлыйсыз, чолганыш бозҗрасын өзеп чыгарга сезнең берничнди дә реаль мөмкинлекләрегез юк. Сезнең хәлегез өметсез һәм артык каршылык күрсәтүнең берничнди дә мәгънәсе юк.

Сезнең өчен туган котылгысыз шартларда, урынсызга кан түгүне булдырмау өчен, сезгә түбәндәгечә капитуляция шартларын кабул итәргә тәкъдим итәбез: 1) башында сез һәм сезнең штабыгыз тора торган, чолганып калган барлык Германия гаскәрләренең каршылык күрсәтүен туктатырга; 2) сезгә бөтен личный составны, коралларыгызны, бөтен сугыш техникасын һәм сугыш милекләрен төзек хәлендә, оешкан төстә безнең карамакка бирергә.

Каршылык күрсәтүне туктаткан барлык офицерларга һәм солдатларга без яшәү һәм куркынычсызлык, ә сугыш беткәннән соң Германиягә яки хәрби пленныйлар үзләре теләгән никди булса да илгә кайтаруны тәэмин итәбез.

Бирелгән гаскәрләрнең бөтен личный составының хәрби формасын, аерымлык билгеләрен һәм орденнарын, личный әйберләрен, кыйммәтле нәрсәләрен, ә югары дәрәҗәле офицерлар составының салкын коралларын да саклап калырбыз.

Бирелгән офицерларның, унтер-офицерларның һәм солдатларның барысына да кичекмәстән нормаль туену билгеләнер.

Барлык яралыларга, авыруларга һәм өшегәннәргә медицина ярдәме күрсәтелер.

Сезнең җавабыгыз 1943 нче елның 9 нчы январенда, Москва вакыты белән

(Ахыры 4 нче биттә).

ОБОРОНА ХАЛЫК КОМИССАРЫ ПРИКАЗЫ

15 январь, 1943 ел. *№ 25* *Москва шәһәре*

ЯҢА АЕРЫМЛЫК БИЛГЕЛӘРЕ КЕРТҮ ТУРЫНДА ҺӘМ КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ КИЕМ ФОРМАЛАРЫНДА ҮЗГӘРЕШЛӘР ТУРЫНДА

ССР Союзы Верховный Советы Президиумының «Кызыл Армиянең личный составы өчен яңа аерымлык билгеләре кертү турында» 1943 нче елның 6 нчы январь указына туры китереп—

Приказ бирәм:

1. Погоннар куеп йөрүне кертергә:

кыр погоннары—Хәрәкәттәге Армиядәге хезмәткәрләргә һәм фронтка җибәрү өчен әзерләнә торган частьларның личный составына;

көндәлек погоннар—Кызыл Армиянең башка частьларының һәм учреждениеләренең хәрби хезмәткәрләренә, шулай ук киемнең парад формасын кигән чакта.

2. Кызыл Армиянең бөтен личный составына—1943 нче елның 1 нче февраленнән 15 нче февралена кадәр булган чорда яңа аерымлык билгеләренә—погоннарга күчәргә.

3. Кызыл Армиянең личный составының кием формасына язма аңлатма буенча үзгәрешләр кертергә.

4. «Кызыл Армиянең личный составының кием формасын кию кагыйдәләрен» гамәлгә кертергә.

5. Гамәлдәге сроклар һәм тәэмин нормалары буенча чираттагы обмундирование бирелгәнчегә кадәр хәзерге кием формасын яңа аерымлык билгеләре белән киеп йөрергә рөхсәт итәргә.

6. Частьларның командирларына һәм гарнизоннарның начальникларына,—кием формасын саклауны һәм яңа аерымлык билгеләрен дөрес итеп куеп йөрүне бик нык күзәтеп торырга.

Оборона Халык Комиссары И. СТАЛИН.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ XXV ЕЛЛЫГЫН ЯҢА ҖИҢҮЛӘР БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙК!

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШ КӨЧӘЯ

Завком председателе урынбасары иптәш Иванов булган Н-че завод коллективы эшләп чыгаруны үстерү, нормаларны арттырып үтәү һәм бернинди дә брак булдырмау буенча конкрет йөкләмәләр алып, ярышып эшли. Заводта барысы да сөекле Кызыл Армиябезнең 25 еллыгына тагын да матуррак хезмәт үрнәкләре бирү теләге белән яналар.

Начальнигы иптәш Берницев булган цех хәзер иң алда бара; бу цех январь аенда бер партия өстәмә продукция бирәчәк. Норманы 130—140 процентка үтәп, бөтенләй брак бирмәгән иптәш Федоров бригадасы—алдынгы цехның алдынгы бригадасы булып исәпләнә. Заводка ватан сугышы башлангач кына килеп, бик тырышып эшли башлаган Вәлиуллина, Солтанова, Гениксоң кебек иптәшләр бу цехта аз түгел; күптән түгел генә эшли башлаган бу иптәшләр айлык нормаларын 115 процентттан алып, 150 процентка кадәр үтиләр.

Начальнигы иптәш Шурунов булган цех коллективы ярышта икенче урында бара, ләкин ул беренче урын өчен уңышлы рәвештә көрәшә. Бу цехтагы Гыйлаҗетдинов бригадасы членнары заданиеләрен уртача 125 процентка үтәп киләләр. Цехның иң яхшы наладчигы, бригадир иптәш Гыйлаҗетдинов үзе аеруча зур дәрт белән ярышып эшли: ул һәрвакыт эштәге бөтен җитешсезлекләрне бетерә килә һәм, инде генә шартлар туа торсалар да, станокларга простой ясамый.

Сөекле Кызыл Армиябезнең 25 еллыгын лаеклы рәвештә каршы алу өчен социалистик ярыш бөтен завод коллективы членнары арасында көннән-көн киңәя, дәртләнә, үсә.

И. Туктар.

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

Баулы районында ашлык һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләүнең барышы турында

Баулы районы берничә еллар буена ашлык әзерләү планнарын үтәми килә, башка төрле хуҗалык-политик чараларны үткәрүне дә өзә. 1942-43 нче елны да хәл яхшырмаган—ашлык әзерләү планы бары 25,6 процентка гына үтәлгән, МТС ларның эшенә натуралата түләү Баулы МТС ы буенча планга карата 28,4 процент һәм Поповка МТС ы буенча 17,2 процент кына кергән.

Баулы районы җитәкчеләре һәм аерым алганда район советы башкарма комитеты председателе Ананьев, берничә тапкыр кисәтү ясалуга да карамастан, ашлык тапшыруны көчәйтү чараларын күрмәгәннәр, ашлык әзерләүгә саботаж ясаучылар белән килешеп торганнар, ә еш кына аларны яклаганнар. Шушындый оппортунистлык практикасы нәтиҗәсендә районның күп кенә колхозларында ашлык сугу ясалма рәвештә тоткарланган, саклау һәм контроль булмаганлыктан ашлык урланган.

Башка продуктлар әзерләү ягыннан да эш ачыктан-ачык начар тора: бәрәнге әзерләү планы 43 процентка, яшелчә әзерләү 30,8 процентка, печән тапшыру 32 процентка, ит тапшыру буенча еллык план 74,6 процентка гына үтәлгән. Ә шул ук вакытта республика буенча ит тапшыру планы инде арттырып үтәлде.

Баулы районында әзерләүләрнең барышы турындагы мәсьәлә ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросында тикшерелде. Ашлык һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләүне өзгән өчен, саботажникларга юл куйган өчен Баулы район советы башкарма комитеты председателе Г. В. Ананьев эшеннән алынды, партиядән чыгарылды һәм хәрби трибунал судына бирелде.

ВКП(б) ның Баулы райкомына һәм район советы башкарма комитетына хәлне төзәтү өчен бик тизлек белән тулы чаралар күрергә, ашлык һәм башка авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү планнарының тулысынча үтәлүен тәэмин итәргә тәкъдим ителде.

АЛГАН ЙӨКЛӘМӘЛӘРНЕ НАМУС БЕЛӘН ҮТИЛӘР

Завком председателе урынбасары иптәш Кисарина булган Н-че завод коллективы ватан алдында, Кызыл Армия алдында биргән вәгъдәләрен намус белән үти. Заводның барлык цехларында да производство графигы төгәл үтәлә. Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә сталинчы вахтага басып, ярышып эшләү гүзәл нәтиҗәләр бирә. Начальнигы иптәш Аполонников булган цех задание буенча һәр сменага 70 изделие урынына, 75 изделие эшләп чыгара.

Начальнигы иптәш Әҗмитов булган цех бу ярышта аеруча зур уңышларга ирешә. Цехның көндәлек планы —32 данә изделие эшләп чыгару. Ләкин бу планны үтәү генә цех коллективын һич тә канәгатьләндерми. Алар, героик Кызыл Армиягә күбрәк һәм күбрәк продукция бирү өчен көрәштә эш темпларын һаман үстерә барып, хәзер һәркөн саен 50 данә изделие эшләп чыгаруга ирештеләр.

Заводның цехларында хәзер сәгатьлек график кертелгән. Нормаларны, планнарны үтәүдә һәм арттырып үтәүдә моның бик зур ярдәме тия. Бөтен сменада гына түгел, бәлки һәрбер сәгатьтә күпме продукция чыгарылырга тиеш һәм күпме чыгарыла икәнлеген барлык эшчеләр дә төгәл белеп торалар. Эштә килеп чыккан тоткарлыклар шунда ук бетереләләр. Заводта эш көненең һәрбер сәгатен һәм минутын нәтиҗәле итеп үткәрү өчен көрәш уңышлы алып барыла.

САМОЛЕТЛАР ТӨЗҮГӘ

АПАС, 16 январь. (Телефон буенча). Бөек юлбашчының котлавына районның күп кенә колхозларында эшлекле җавап бирү өчен көрәшәләр. Самолетлар эскадрильясы төзү фондына кертелгән средствоның күләме көннән-көн үсә бара.

«Тырышчы» колхозы членнары даһи Сталинның котлау телеграммасын укыгач, самолетлар эскадрильясы төзү өчен тагын 135 мең сум бирергә булдылар һәм шунда ук акча кертә башладылар. Колхоз председателе иптәш Галиев 45.000 сум бирде. Колхозчылар тиз көндә үзләренең вәгъдәләрен үтәделәр. 135.000 сум акча тулысы белән дәүләт банкасына тапшырылды.

Карл Маркс исемендәге колхоздан да 135.000 сум средство тупланды. Районда юлбашчыга биргән вәгъдәләрен үтәгән колхозларның саны көннән-көн арта. Район самолетлар төзүгә 1 миллион 400 мең сум акча тапшырды.

—Безнең саклык акчаларыбыз, дошманга ут ядролары яудыра торган самолетларга әверелеп, гитлеризмны мәңгегә юк итүдә ярдәм итсеннәр,—диләр колхозчылар.



Н-че завод стахановчысы М. Михайлова фронт заказлары буенча смена заданиеләрен 300 процентка үтәп бара.
ТАСС фотохроникасы.

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ УРНЫНДА

ДӘҮЛӘТ ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕН ҮТӘҮДӘ РАЙОН ГАЗЕТАЛАРЫ

Сугыш шартларында илебез алдына гаять зур яңа бурычлар килеп басты. Бөтен көч, барлык средстволар, барыннан да элек, ил интересларына, явыз дошманны тар-мар итү интересларына буйсындырылган булырга тиеш.

Завод-фабрикалар фронт өчен җитәрлек күләмдә танклар, самолетлар, орудиеләр, пулеметлар һәм башка сугыш кирәк-яраклары эшләп чыгарырга тиешләр. Авыл хуҗалыгы исә илне һәм фронтны икмәк, ит, май кебек продуктлар һәм тире, йон, сүс кебек чимал белән мул тәэмин итәргә тиеш. Дошманны тизрәк тар-мар итү әнә шуларга нык бәйләнгән.

Алда әнә шундый гаять катлаулы һәм җаваплы бурычлар торган бер чорда большевистик матбугатның роле тагын да үсте. Хуҗалыкның һәрбер тармагында большевистик матбугат үзенең коллектив агитатор һәм пропагандист, коллектив оештыручы булучанлыгын берничә кат арттырырга тиеш.

Сүз, илне һәм фронтны авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итү турында бара икән, колхозларның һәм совхозларның дәүләт йөкләмәләрен срогында, яхшы сыйфатлы итеп үтәүләрендә район газеталарының бурычы — бу эшкә массаны туплаудан гыйбарәт. Район газеталары дәүләт йөкләмәләрен яхшы үтәүче колхозларның һәм совхозларның тәҗрибәләрен киң күләмдә популярлаштырырга, бу турыда колхозчыларга ачык, аңлаешлы итеп сөйләп бирергә, эшне өзеклеккә төшерүчеләрне, саботажникларны фаш итәргә, аларны большевистик тәнкыйть астына алырга тиешләр. Кулына газета тоткан һәрбер колхозчы районда һәм аерым колхозларда эшнең барышын белеп торырлык булсын һәм газетаны укыгач та, эшлекле бер нәтиҗә ясарлык булсын. Газетаның коллектив агитатор һәм коллектив оештыручанлык роле дә әнә шунда.

Күп кенә район газеталары исә үзләренең менә бу бурычларын үтәүдән ерак торалар әле. Әлмәт районында чыга торган «Социализмга» газетасының соңгы айларда чыккан номерларына күз салсаң, моның шулай икәнен ачык күрәсең. Бу газета үзенең октябрь һәм ноябрь айларында чыккан бер дистә номерында дәүләткә ашлык тапшыруны тизрәк төгәлләү турында бер баш мәкалә һәм ике хәбәр урнаштыру белән чикләнгән. Бу баш мәкаләне һәм хәбәрләрне укыгач та, шундый бер хәл күз алдына килеп баса: әйтерсеңлә, Әлмәт районында эшләр ал дагөл, районда дәүләт йөкләмәләрен үтәүне өзеклеккә төшерүче колхозлар да юк. Чынлыкта исә Әлмәт районында дәүләткә ашлык тапшыру планы бүгенге көнгә әле яртысы да үтәлмәгән.

Бу баш мәкалә һәм хәбәрләр, редакция работникларының, турыдан-туры әйткәндә, җаваплы редактор өчен кул куйган иптәш Исмәгыйлованың районда дәүләт йөкләмәләрен үтәү өлкәсендә эшнең торышы белән тиешенчә кызыксынмауларын күрсәтә. Аерым хәлләрдә газета эшне таркатучыларның һәм җинаятьчеләрнең гаепләрен икенче бер дәрәҗәдәге сәбәпләргә сылтап калдырган. Газетаның 26 нчы октябрьда чыккан номерында «Таң» колхозында терлекләрне кышлатуга әзерлекнең начар булуы, терлекләрне үрчетү планының һәм терлекчелек продуктлары буенча дәүләт йөкләмәсенең үтәлмәве турында бер хәбәр урнаштырылган. Хәбәрдә язылганча, бу колхозда дәүләткә сөт тапшыру планы 19 процентка, ит тапшыру планы 47 процентка гына үтәлгән. Аннары хәбәрдә болай диелә: «Фермада терлекләрнең зоотехника нигезендә тәрбияләнәмәве, агитация-масса эшләренең начар булуы (?!) ферма эшчеләре арасында социалистик ярышның киң җәелдерелмәве аркасында 7 ат, 4 тай, бер сыер, 9 сарык һәм 15 баш бәрән үлгән. Шундый зур җинаятьләр була торып та, быел да фермага ремонт эшенә игътибар бирелми».

Ә соң шундый зур җинаятьләр булгач, ул җинаятьләрне эшләүче кешеләр турында нигә газетада бер сүз дә әйтелми! Терлекчелекне үрчетү планын үтәмәүдә, дәүләт йөкләмәләрен үтәүне өзүдә, ниһаять, күп санда терлекләрнең үлүләренә юл куюда гаепле кешеләр, әгәр терлек абзарларына ремонт ясауга игътибар бирсәләр, шуның белән акланып калырга тиешләрмени? Газета, ферманы шул хәлгә калдыручы кемгә дә булса җинаятьче тамгасы баскан икән, бу турыда ул большевистик матбугатка хас булган үткен тел белән үзенең ачык фикерен әйтергә тиеш иде.

Авыл хуҗалыгы продуктлары тапшыру буенча дәүләт йөкләмәләрен тулысынча һәм арттырып үтәү—бүгенге көндә колхозлар һәм совхозлар алдында торган бик әһәмиятле һәм гаять җаваплы эшләрнең берсе. Бу эшне уңышлы үтәү өчен көрәштә район газеталарының бурычы—дәүләт йөкләмәләрен үтәү турында үзләренең битләрендә тирән эчтәлекле материалларны системалы рәвештә биреп барырга һәм ул материалларның нәтиҗәлелеге өчен көрәш оештырудан гыйбарәт. «Социализмга» газетасы работниклары үзләренең бу өлкәдәге җитешсезлекләрен кичекмәстән бетерүдә чын-чынлап уйларга һәм газетаның эшен хәзерге шартлар таләп иткән югарылыкка күтәрергә тиешләр. Шулай ук ВКП(б) ның Әлмәт райкомы да үз газетасының эше белән якыннан кызыксынырга, аның эшен яхшыртуда конкрет ярдәм күрсәтергә тиеш.

Бер туган дус семья. Сулдан уңга—сержант үзбәк Абдылкасым Рахманов, кызыл армеец алтаец Василий Менкушев, старшина казах Туктарбай Бакиров, өлкән сержант осетин Георгий Кочиев, кече лейтенант шорец Михаил Кыдимов, сержант татар Минһаҗ Габитов (Апас районы), өлкән сержант казах Аманбек Кульжанбеков, сержант татар Һади Фаррахов (Минзәлә районы), кызылармеец казах Алтынбек Жансибаев.

Б. Эйберг һәм А. Авербах фотосы.

ОЧНЫННАР

I. ЯҢА ДУСЛАР

Алар килделәр... Алар безгә утлы чаткылар булып очып килеп төштеләр. Әллә нигә, гомумән, бик күңелле һәм шатлыклы булып китте. Гүяки, авыр һәм газаплы солдат тормышына зур бер хәз булды...

Алар килделәр. Алар безгә озын һәм суык кыш узгач очып килгән беренче карлыгачлар кебек, җәйге эссе һәм тузанда кинәт әллә кайдан исеп киткән салкынча һәм саф җил кебек булдылар.

— Ишеттеңме? Безгә сталинградлылар килгәннәр. Сталинград төбендә сугышта булганнар. Әнә, әнә, старшина алар өчен бияләйләр алган. Әйдә, алар янына!

— Ишеттеңме? Беренче взводта ике яңа кызылармеец бар. Килә килгәннәр. Сталинград төбендә яраланып, сәламәтләнгәннән соң, безнең фронтка килеп чыкканнар... Сора командирыңнан, барабыз анда... Мин командирымнан рөхсәт алдым...

... Землянка җылы һәм матур. Каршыда мич яна. Мич янында таныш булмаган бер кызылармеец тәмәке ясый, тәмәке тарта һәм сөйли... Анда тагын берничә таныш булмаган иптәшләр бар. Юка гына зәңгәрсу томан—тәмәке төтене тәрәзә яктысында озын булып тора. Землянка тыныч һәм сугышчылар белән тул-тулы.

— Ярар, егетләр,—диде яңа кызылармеец,— алай булгач, мин сезгә мәңге онтылмаслык бер калай түбә турында сөйлим...

2. КАЛАЙ ТҮБӘ

— Төшенә кермәсен, егетләр, ул коточкыч һәм йөрәк яргыч сугыш, валлаһи, акылдан язарсың. Өнеңдә булса түзәсең икән, егетләр! Минем әби сөйли иде, мәрхүм. Җәһәннәм, тагын шунда әллә нинди коточкыч хәлләр... Ярар, сезгә сугыш дәһшәтләрен сөйләп тормыйм, сез үзегез дә шуның эчендә бит.

Без бер взвод идек. Урамның бер ягы безнең кулда. Каршы ягы немецта. Урам—нейтраль зона. Аның бер башында безнекеләр, каршы башында тегеләр. Безнең взвод җимерек таш йорт тирәсендә тора. Каршыда, ничектер исән калган зур йорт. Биш катлы һәм калай башлы.

Таң белену белән без нәкъ шул йортка һөҗүм иттек. Без, миномет, пулемет утына карамастан йортка ыргылып кердек. Безнең иптәшләр немец солдатларын чәнчә-турый барып, беренче каттан алып, бишенче катка кадәр таралыштылар. Мин һәм бер өлкән сержант, ике немец солдатын куып барып, чардакка ук менеп киттек. Берсен чардакта атып ектык. Бер немец исә, чаба-чаба калай түбәгә ук барып чыкты. Мин аның артыннан. Өлкән сержант — минем артымнан. Түбә биек иде, тирә-як коточкыч тавышлар белән гүли иде. Немецка ыргылдым, һәм аның белән түбә өстендә алыша башладык... Без һаман түбә кырыена таба тәгәри идек... Шулай да, немец урам ташына очты. Мин, үзем дә белмим, ничек калганмын. Телисез икән, мин сезгә бер манара турында сөйлим...

3. БЕР МАНАРА

Бу манара тыкрык чатында тора иде, һәм әйтергә кирәк, кечкенә генә булса да матур иде. Көндезен булса—көндезен, төнен булса—төнен немецлар шул манарадан күзәтү эшләрен алып баралар иде. Кай вакыт исә—миномет белән безнең оборонаның арткы өлешләрен тупка тоталар иде.

Без һаман шул манарага якынлаша бардык. Безнең каршыда җимерек йортлар һәм җимерек каралтылар аша узган тимер чыбык киртәләр һәм миналар куелган тебәкләр.

Бар иде бер кече лейтенант. Фамилиясен, исемен белми калдык. Ләкин кем булса да, туфрагы җиңел булсын, ул безнең күңелдә мәңге онытылмаслык бер герой булып калды. Соңыннан сөйләделәр, ул безнең частьның комсомол бюросы члены булган, һәм махсус задание алып, безнең подразделениегә килгән булган.

Без кичен манарага һөҗүм иттек, ләкин аскы катта урнашкан немецлар бик нык каршы тордылар, турыдан удар ясау гаять читен иде, һәм әйтергә кирәк, хәтта мөмкин дә түгел иде.

Кече лейтенант безне позицияләребездә калдырып, үзе уң яклап әйләнеп манара төбенә барып чыкты һәм ул, кичке эңгер-меңгердән файдаланып, сиздерми генә, манараның тышкы ягыннан югарыга үрмәли башлады. Менә ул, тәрәзәчек янына менеп җитте һәм эчке якка бер-бер артлы берничә граната ташлады. Фашистлар арасында буталыш купты. Һәм без, моннан файдаланып, һөҗүмгә күчтек. Уннарча немецны турап салдык. Безнең кече лейтенант исә, гранаталар шартлау белән, манарадан җиргә очып төшә һәм шунда геройларча һәлак була. Эх, иптәшләр, нинди генә кыйммәтләр юк доньяда! Бигрәк тә Сталинград төбендә... Менә тагын бер вакыйга... Мин сезә хәзер гранит таш турында сөйлим...

4. ГРАНИТ ТАШ

Зур бер гранит таш бар иде, ул безнең оборонаның алгы кырыенда мәгърур бер кыяфәт белән ята иде.

Без оборонага урнаштык. Немецлар көн буе, төн буе безгә пулеметтан, минометтан аттылар, безнең өскә самолеттан үлем бомбалары койдылар. Безнең каршыда торган гранит ташка пулялар һәм мина, снаряд китекләре килеп тигән саен, аннан чаткылар чәчелде, таш ватыклары безнең өскә ыргылды, һәм кичкә таба гранит таш бөтенләй юкка чыкты, ул тузан булып, уылып, тузып бетте. Немецлар, без яткан җирдә бу гранит таш уылып беткәч, һичкем исән калмаган, дип ышанып, һөҗүмгә күчтеләр. Ләкин аларны, гранит таштан да нык һәм көчле ватан батырлары өермәле ут белән каршы алып, күренгән һәрбер фрицны кырып сала тордылар. Әгәр тагын телисез икән, мин сезгә яшь калмык турында сөйлим.

...Землянкада тыныч һәм рәхәт. Сугышчылар тәмәке тарта-тарта Сталинград сугышлары геройларының истәлекләрен тыңлыйлар, ә сталинградлылар исә,—үзенең истәлекләрен сөйләгән Назаров, аның каршында утырган Хорторсынов, мич янына утырган Мөхәмбетов үзләрен яңа семьяда бик иркен тоялар иде, һәм биредә дә героик сугышларда катнашу теләге белән яналар иде.

ШӘРӘФ МӨДӘРРИС.

ФРОНТ РӘХМӘТ ӘЙТӘ

Республикабыз колхозчыларының Тамбовчылар инициативасын зур күтәренкелек белән каршылап, «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә акча туплаулары турындагы хәбәр фронтка да барып җитте. Редакция фронттагы сугышчылардан һәм командирлардан колхозчыларга чын күңелдән рәхмәт белдерелгән хатларны бик күп ала. Без шуларның кайберләрен урнаштырабыз.

Безнең тылыбыз нык

Фронтка тылдан газета шатлыклы хәбәр китерде. Бу хәбәр кече лейтенант Шакировны һәм аның якташлары Шәмсетдиновны, Мифтахетдиновны, Әхтәмовны аеруча нык куандырды.

— Республикабыз танклар колоннасы төзүгә 100 миллион сум акча туплаган. Юлбашчының котлавы белән рухланган колхозчылар тагын бердәм рәвештә күтәреләләр. Самолетлар эскадрильясе төзү өчен средство туплыйлар,—диләр алар.

Тылдан килгән газета кулдан-кулга йөри. Татарстан уллары янына аларның коралдаш иптәшләре руслар, украинлылар, белоруслар җыелалар.

— Укы, иптәш Шакиров, тагын бер кат безгә укып аңлат.

Татар газетасында язылган хәбәрләрне һәрбер милләт аңларлык итеп сөйләү өчен уртак тел табыла. Газета уку җыелыш төсен ала, һәм кызылармеецлар җыелышы командирдан Татарстан хезмәт ияләренә рәхмәт белдерүне таләп итә.

«Без, сугышчылар һәм командирлар, сезнең Кызыл Армиягә булган мәхәббәтегезне һәм хөрмәтегезне ишетеп шатландык. Бездә ул яңа көч һәм энергия тудырды. Без үзебезнең нык һәм ышанычлы тылыбызны котлыйбыз. Шундый бердәм һәм көчле тылыбыз булганга күрә дә, без бик яхшы коралланган хәлдә сугышабыз. Җылы киенәбез, туклыклы ашлар ашыйбыз. Безгә салкын кышның иң [illegible] генә зәһәр бураннары да үтми. Нинди генә сынаулар да безне куркытмый. Тылның тырышлыгы безне беренче дәрәҗәдәге сугыш техникасы белән коралландырды. Аны фашист этләргә каршы көрәштә, оста рәвештә кулланабыз. Гитлеризмны мәңгегә юк итү өчен бездә барлык мөмкинлекләр дә бар.

Нык тылыбызның эшчән кешеләре, мактау һәм дан сезгә! Фронттагы улларыгызга тагын да күбрәк кораллар һәм башка сугыш припаслары житештерү өчен көрәшегез. Бу хәл дошманны җиңү сәгатен һәм безнең сезнең белән күрешү көнен якынайтыр.

Часть командиры **ГЕЗЕРДАВА».**

Синең егетләрең куркусызлар

Кадерле иптәшләр!

Безнең бу хатыбыз сезгә барып житкәндә без ерак юллар үткән булырбыз. Безнең бөтен омтылышыбыз—немец оккупантларын тизрәк тар-мар итеп, илне дошманнан коткару.

Без сезнең яннан аерылып киткәндә биргән вәгъдәбезне аклау өчен армый-талмый көрәшеп, яңадан-яңа җиңүләргә ирешербез.

Туган илебезнең хезмәт ияләреннән Кызыл Армия өчен миллионнарча суммалар җыелуы турында ишеткәч, без үзебезнең Татарстан халкының тавышын өзелеп көттек.

Менә ул хәбәр: безнең орденлы Татарстаныбыз 100 миллион сум средство туплап, танклар колоннасы әзерли. Бу хәбәрне газетадан укыгач, колхоз картларының кулларын каты итеп кысасы, үзенең көчен кызганмыйча армый-талмый эшли торган житез кызларны үбәсе, республикабызның барлык хезмәт ияләренә чын күңелдән рәхмәт белдерәсе килде. Рәхмәт сезгә, иптәшләр! Без дә сезне онытмыйбыз.

Татарстан! Синең егетләрең куркусызлар, синең бәхетең өчен, киләчәк якты тормышың өчен монда килдек без.

Безнең танклар дошманга мәңге төзәлмәслек яра ясаячаклар әле. 1943 нче ел җиңү елы булыр. Тыныч бул, Татарстан! Без чыныктык хәзер. Безнең күңелләрдә бер генә уй—тизрәк дошманны тар-мар итү. Без җиңәрбез, уңышлыклар белән көтегез безне, иптәшләр!

Кайнар сәлам белән лейтенант
Г. СӨЛӘЙМАНОВ һәм **З. СӨНГАТОВ.**

Без сынатмыйбыз

Совет иленең барлык колхозчылары үзләренең саклык акчаларын Кызыл Армиягә [illegible] кораллар төзүгә бүләк итәләр. Орденлы республикабызның да 100 миллион сум средство туплап, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның рәхмәтенә лаеклы булуын ишетеп без бик шатландык.

Без, татар халкының куркусыз уллары Советлар илендәге барлык милләтләрнең батыр сугышчылары белән берлектә бик дус хәрәкәт итәбез. Республикабыз, тыныч эшлә, тырышып эшлә. Илебезне дошманнардан тазарту өчен, немец оккупантларын тагын да күбрәк кыру өчен яңадан-яңа танклар, авиаэскадрильялар төзеп бир.

Без, орденлы Татарстан уллары үз эшебездә сынатмабыз. Вәхши дошманны тәмам кырып бетереп, илебездә, элеккечә, рәхәт, матур, тыныч тормыш урнаштырырбыз.

Сугышчылар: **МӨХӘМӘТЬЯРОВ, ХӘЙРЕТДИНОВ, ГАРИФУЛЛИН, РӘХИМОВ, БИКТИМЕРОВ, БАРИЕВ, ТУКАЕВ, ИСХАКОВ, МӨНАСИПОВ, КОРБАНОВ, РӘХМӘТУЛЛИН, ЯРМӨХӘМЕТОВ, ҖАМАЛИЕВ, БАЛТАНБАЕВ.**

Республика, тыңла!

Без, Татарстанның иркен кырларында, чәчәкле болыннарында, матур урманнарында, төзек шәһәрләрендә үскән яшьләр фашизмга каршы барган канлы көрәштә каныбызны да, тормышыбызны да аямыйча көрәшәбез.

Республиканың эшчән халкы, тыңла! Тырышлыгың, ярдәмең өчен зур рәхмәт сиңа. Без сезнең халкыбызның хезмәте аша житештерелгән кораллар белән немец этләрен кырабыз. Хәзерге көндә безнең хисапта үтерелгән фрицларның, җимертелгән һәм кулга төшерелгән немец танкларының, пушкаларының саны исәпсез күп. Бу хисапны тагын да арттырып, көннән-көн алга барабыз.

Сезнең средствога эшләнгән сугыш машиналары дошманга тагын да дәһшәтлерәк үлем китерерләр.

1943 нче елда, фронт өчен корал һәм башка кирәк әйберләрне житештерүне тагын да арттырырсыз дип ышанабыз.

Алга, яңа җиңүләргә, кадерле иптәшләр!

Өлкән лейтенант **М. ШАКИРЖАНОВ.**
Наводчик **К. НУРИЕВ.**

Соңгы сәгатьтә

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

10 сәгать 00 минутта көтелә. Җавап язма формада булырга тиеш. Җавапны сезнең үз тарафыгыздан билгеләнгән вәкил китерергә тиеш. Ул Конный разъездына—Котлубань станциясенә килә торган юлдан, ак флаг куелган җиңел автомобиль белән килергә тиеш. Сезнең вәкилегезне 564 нче разъездан 0,5 километр көньяк-көнчыгыштарак «Б» районында 1943 нче елның 9 нчы январенда 10 сәгать 00 минутта русларның доверенный командирлары каршы алырлар.

Әгәр дә сез капитуляция турындагы безнең тәкъдимне кире кагасы булсагыз, кисәтү ясыйбыз, Кызыл Армия һәм Кызыл Һава Флоты гаскәрләре эшне чолганып алынган Германия гаскәрләрен юк итүгә алып барырга мәҗбүр булачаклар, ә аларның юк ителүе өчен сез җаваплы булачаксыз.

Кызыл Армиянең Верховный Баш Командованиесе Ставкасы вәкиле артиллерия генерал-полковнигы ВОРОНОВ.

Дон фронты гаскәрләре командующие генерал-лейтенант

РОКОССОВСКИЙ».

Сталинград янында чолгап алынган немец-фашист гаскәрләрнең командованиесе совет командованиесенең ультиматумын кире какты.

Шунлыктан 10 нчы яварьда безнең гаскәрләр Сталинград районында чолганып алынган немец-фашист гаскәрләренә каршы генеральный атака башладылар. Каты сугышларның 7 көне эчендә безнең гаскәрләр немец-фашист гаскәрләрне чолгап алган боҗраны кысып, аерым юнәлешләрдә 20—35 километр алга киттеләр һәм ныгытылган әһәмиятле оборона узелларыннан **Мариновканы, Атаманскийны, Ворошилов исемендәге лагерьны, Карповканы, Жирноклеевканы, Госпитомникны, Снеоковскийны, Новый Рогачикны, Старый Рогачикны, Песчаныйкарьерны, Береславскийны, Скляровны, Ракотиноны, Кравцовны, Цыбенконы, Елхины, Алексеевканы, Питомникны, Дубининны, Малая Россошканы, Заподновканы, Бородинны, Совхоз № 1 не, Бабуркинны, Ново-Алексеевскийны, Дмитриевканы, Полтавскийны, Оторвановканы, Соловьевны һәм тимер** юл станцияләреннән **Басаргиноны, Карповскаяны, Прудбойны** алдылар.

Һөҗүмнең 7 көне эчендә безнең артиллериябез һәм минометларыбыз 1526 ныгытылган узелны һәм блиндажны, нык итеп ясалган 75 күзәтү пунктын җимерделәр һәм сугышта дошманның 317 артиллерия һәм миномет батареясын юк иттеләр һәм бастырдылар.

565 квадрат километр зурлыктагы территория дошманнан чистартылды.

10 нчы январьдан 16 сына кадәр булган һөҗүм вакытында безнең гаскәрләр 6.896 немец солдатын һәм офицерын плен алдылар.

Шул ук вакыт эчендә түбәндәге трофейлар кулга төшерелде: самолетлар—371, танклар—514, төрле калибрдагы орудиеләр—941, минометлар—470, шулардан 6 көпшәлеләр—50, пулеметлар—1.950, винтовкалар—16.308, автомашиналар—15.551, мотоцикллар—1.387, тягачлар һәм транспортерлар—67, сугыш милекләре төялгән повозкалар—1.408, радиостанцияләр—54, бронепоездлар—3, паровозлар—10, вагоннар—100, сугыш припаслары һәм кораллар тутырылган складлар—63, шулай ук бик күп санда снарядлар, авиабомбалар, миналар, гранаталар, винтовка патроннары һәм башка төрле күп хәрби милекләр.

Дошманның 75 самолеты, 174 танкысы, төрле калибрлардагы 416 орудиесе, 140 минометы, 769 пулеметы, 414 автомашинасы, һәр төрле 9 складьы юк ителде.

Сугышларның 7 көне эчендә дошман, үтерелгән хәлдә генә дә, 25.000 нән артык солдат һәм офицерларын югалтты.

Дошман оборонасын өзү Дон фронтының генерал-полковник иптәш **К. К. Рокоссовский** командалыгындагы көчләре белән тормышка ашырылды. Артиллерия һөҗүмен оештыруга Верховный Баш Командование Ставкасы вәкиле артиллерия генерал-полковнигы иптәш **Н. Н. Воронов** җитәкчелек итте.

Сугышларда генерал-майор иптәш **И. М. Чистяков,** генерал-майор иптәш **Ф. И. Толбухин,** генерал-лейтенант иптәш **П. И. Батов,** генерал-лейтенант иптәш **М. С. Шумилов,** генерал-майор иптәш **И. В. Галанин,** генерал-лейтенант иптәш **В. И. Чуйков,** генерал-майор иптәш **А. С. Жадов** гаскәрләре үзләрен аеруча күрсәттеләр.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

16 нчы ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

16 нчы январьга каршы төндә безнең гаскәрләр **Төньяк Кавказда, Донның** түбәнге агымы һәм **Төньяк Донец** районында элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең штурм отрядлары алга киттеләр һәм күп кенә ныгытылган биналарны алдылар. Дошманның 200 дән артык солдат һәм офицерлары, 6 орудиесе, 3 миномет батареясы һәм 26 ут точкасы юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды. Бер участокта немецларның бер рота пехотасы контратакага күчкән иде, ләкин безнең подразделениеләрнең пулемет һәм миномет уты белән бөтенләй диярлек кырып бетерелде.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр, дошманның нык лы каршылык күрсәтүен җиңеп, уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Бер участокта немецлар куәтле оборона полосасы төзегән булганнар. Н-че берләшмә частьлары, дошманның ныгытмаларына флангларда н үтеп, аның оборонасын таркаттылар һәм гитлерчыларны зур югалтуларга дучар иттеләр. Дошманны куып барып, безнең частьлар халык яшә торган берничә пунктны алдылар. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Үзәк фронтта, Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак, дошман пехотасы һәм танклары, артиллерия хәзерлегеннән соң, Н-че часть позицияләренә атака ясадылар. Безнең артиллеристлар, тиз генә орудиеләрне ачык позицияләргә алып чыгып, немецларның 4 авыр танкысын зарарладылар. Безнең сугышчылар танклар ярдәменнән мәхрум калган немецлар пехотасын штык удары белән алып ташладылар. Дошман сугыш кырында 180 үле гәүдә калдырды.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар. Иптәш Хоменко командалыгындагы сугышчылар бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр. 8 немец танкысын сафтан чыгардылар, 29 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр 200 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр, азык төялгән бер тимер юл эшелонын, 4 орудие һәм 10 миномет кулга төшерделәр. Н-че часть сугышчылары халык яшә торган бер пунктны алган чакта немецлардан 10.000 баш мөгезле терлек сугышып алдылар. Бу терлекләрне гитлерчылар крестьяннардан талап алган булганнар.

* * *

Төньяк Кавказда хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды немец басып алучыларга каршы сугышларда 200 дән артык дошман солдатын һәм офицерын кырган, дошманның 3 бронемашинасын, 7 автомашинасын, 2 радиостанциясен юк иткән һәм ягулык тутырылган зур бер складны яндырган. Партизаннар немецлар частеның байрагын, күп кораллар һәм сугыш припаслары кулга төшергәннәр.

* * *

Курск шәһәрендә немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турында хәбәр алынды. Немец басып алучылар шәһәр халкын кыралар. Декабрь аенда гына да гитлерчы палачлар 500 дән артык кешене газаплап һәм атып үтергәннәр. Январь башында гестапочылар совет интеллигенциясеннән күп кешеләрне кулга алганнар. Кулга алынучыларны газаплаганнар. Гыйльми сотрудник Тимофеевны фашист ерткычлар танылмаслык хәлгә китергәннәр һәм гәүдәсен чүп чокырына ташлаганнар. Немецлар укытучы Михаил Соколовны асып үтергәннәр. Кулга алынган башка кешеләрнең язмышы турында бернәрсә дә билгеле түгел. Шәһәр көннән-көн бушый. Ярты ел эчендә немецлар күмеңнәрчә кешеләрне Германиягә ирексезләп каторгага алып киткәннәр. Шәһәрдә калган халыкны гитлерчылар авыр эшләргә куалар. Эшләүчеләргә хәтта икмәк тә бирелми. Көн саен дистәләрчә кешеләр ачлыктан үлә.

* * *

Нант районында Франциянең азат укчылары немецларның бер ягулык складын шартлатканнар. Лилльдә кораллы французлар танкларга ремонт ясый торган мастерскойны туздырганнар. Ремонт ясалган 6 уртача танк сафтан чыгарылган. Амьен якынында Франция патриотлары немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар

16 нчы ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

Воронеждан көньяктарак урнашкан безнең гаскәрләр шушы көннәрдә немец-фашист гаскәрләргә каршы һөҗүмгә күчтеләр һәм дошманның көчле рәвештә ныгытылган оборонасын өзеп, 50—90 километр алга киттеләр. Безнең гаскәрләр халык яши торган 600 дән артык пунктны, шул исәптән **Россошь** шәһәрен һәм тимер юл узелын, район үзәкләреннән һәм тимер юл станцияләреннән **Олховатканы, Митрофановканы, Пуховоны,** район үзәкләреннән **Репьевканы, Красноены, Ровенькины, Марковканы, Каменьканы,** тимер юл станцияләреннән **Мелогорьены, Рыбальчиноны, Сотницкоены** алдылар.

10 нчы январьда **Дон** фронты гаскәрләре Сталинград районында чолгап алынган немец-фашист гаскәрләренә каршы генеральный атака башладылар. Каты сугышларның 7 көне эчендә безнең гаскәрләр, немец-фашист гаскәрләрне чолгап алган боҗраны кысып, аерым юнәлешләрдә 20—35 километр алга киттеләр һәм әһәмиятле ныгытылган оборона узелларыннан **Мариновканы, Атаманскийны,** Ворошилов исемендәге лагерьны, **Карповканы, Жирноклеевканы, Госпитомникны, Синеоковскийны, Новый Рогачикны, Старый Рогачикны, Песчаный карьерны, Береславскийны, Скляровны, Ракотиноны, Кравцовны, Цыбенконы, Елхины, Алексеевканы, Питомникны, Дубининны, Малая Россошканы, Западновканы, Бородинны, совхоз № 1 не, Бабуркинны, Ново-Алексеевскийны, Дмитриевканы, Полтавскийны, Оторвановканы, Соловьевны** һәм тимер юл станцияләреннән **Басаргиноны, Карповскаяны, Прудбойны** алдылар.

Төньяк Кавказда һәм **Төньяк Донец** районында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр.

* * *

15 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 120 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 тимер юл составын җимерделәр, бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Зимовники районында безнең гаскәрләр дошман танкларының һәм пехотасының нык лы каршылык күрсәтүен җиңеп һәм аларның контратакаларын кире кайтарып, уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Двойная тимер юл станциясе һәм Орловская район үзәге өчен булган сугышларда немецлар авыр югалтуларга дучар ителделәр. Төнлә белән безнең частьлар Орловскаяга бәреп керделәр һәм гитлерчыларны кыра башладылар. Тулы булмаган саннарга караганда, дошманның «Викинг» исемле СС дивизиясеннән 700 дән артык солдат юк ителгән. Исән калган немецлар, миналар куелган азык складларын шартлатырга өлгермичә, паникага бирелеп качтылар. Поселокта һәм станциядә күп санда төрле сугыш милекләре кулга төшерелде. Трофейлар арасында 20 паровоз, 120 вагон һәм платформа, бер бронепоезд, 9 орудие, 3 танк, 40 автомашина, 4.000 тонна ашлык һәм 5 азык склады бар. Шуның өстенә Двойная станциясе өчен булган сугышта дошманның 9 танкысы, 6 орудиесе, 9 минометы, 14 станоклы пулеметы һәм 17 автомашинасы юк ителде. Безнең гаскәрләр, уңышны җәелдереп, халык яши торган тагын берничә пунктны алдылар.

* * *

Төньяк Донец районында безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга бардылар. Н-че кавалерия часте дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган 5 зур пунктны алды. Сугыш кырында дошманның 400 гә якын үле гәүдәләре калды. Безнең башка частьлар гитлерчыларны халык яши торган тагын берничә пункттан бәреп чыгардылар. Дошман бөтен көче белән каршылык күрсәтте һәм контратакага бик күп пехота һәм танклар җибәрде. Гитлерчыларның барлык контратакалары алар өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды. 1.200 гә якын дошман солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Дошманның 29 танкысы, 5 бронемашинасы, 6 орудиесе һәм 70 автомашинасы яндырылды һәм зарарланды. 6 төзек танк, 9 орудие, күп автомашиналар һәм йөк төялгән олаулар кулга төшерелде. Безнең гаскәрләр Глубокая станциясен алган чакта 57 паровоз, 100 дән артык вагон, 5 склад, ашлык тутырылган бер элеватор һәм күп санда төрле хәрби милекләр кулга төшерелде.

* * *

Великие Лукидан көньяк-көнбатыштагы районда немецлар пехотасы, 40 танк ярдәме белән Н-че часть позицияләренә контратака ясады. Бик каты сугышлар көн буе барды. Безнең сугышчылар берничә йөз гитлерчыны кырдылар, дошманның 8 танкысын сафтан чыгардылар һәм дошманны элекке позицияләренә алып ташладылар. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары дошман гаскәрләренең бер группасын тар-мар иттеләр һәм берничә терәк пунктны алдылар. Бер батальонга якын немец пехотасы юк ителде. 470 немец солдаты һәм офицеры плен алынды, 4 танк һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугышлар нәтиҗәсендә халык яши торган берничә пунктны алдылар. Иптәш Кириченко командалыгындагы гвардияче кавалерия частьлары дошманның туздырылган частьларын туктаусыз куып баралар. Халык яши торган бер зур пункт өчен булган сугышларда кавалеристлар 400 гә якын гитлерчыны юк иттеләр, дошманның берничә танкысын һәм бронемашинасын сафтан чыгардылар һәм пленныйлар алдылар.

* * *

Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче берничә партизан отрядлары ике атна эчендә немецның 16 хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. 15 паровоз, 256 вагон, платформа һәм цистерналар җимерелгән. Һәлакәт нәтиҗәсендә 500 ләп гитлерчы үлгән. Бик күп сугыш техникасы һәм сугыш припаслары юк ителгән.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27. редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75. промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 617. «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 113